РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» март 2021 г. г. Альметьевск № 27

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәр Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәр Советының 2006 елның 27 гыйнварындагы 26 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 29 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 21 июлендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәр Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында» 2006 елның 27 гыйнварындагы 26 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәр Советы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының 2013 елның 04 июлендәге 105 номерлы, 2015 елның 13 мартындагы 170 номерлы, 2015 елның 10 декабрендәге 21, 2017 елның 27 июлендәге 88 номерлы, 2018 елның 11 маендагы 115 номерлы, 2019 елның 25 мартындагы 148 номерлы, 2019 елның 25 октябрендәге 176 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 191 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга кушымтада:

1.1.1. 13 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш естәргә:

«4. Шәһәр Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен, тулаем алганда аена алты эш көненнән дә артык булмаган чорда эш урынын (вазыйфасын) саклап калу гарантияләнә.»;

1.1.2. 19 статьяның 4 өлешендәге өченче абзацта «(оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар),» сүзләрен «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләренә алмаштырырга.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм

Зак. № 2624

«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.Ә.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов